**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

29.03.2016_ г.Казань №01-02/114

Юридик затлар исемнәрендә "Татарстан Республикасы", "Татарстан" атамаларын һәм алар нигезендә ясалган сүзләр һәм сүзтезмәләрне (шул исәптән кыскартылмаларны да) куллануга Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2012 елның 14 июнендәге № 01-02/40 номерлы Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 14 декабрендәге "Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының дәүләт хезмәтләре күрсәтү административ регламентын эшләү һәм раслауның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 02 ноябрендәге "Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында" № 880 номерлы карары белән расланган Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында" № 946 номерлы карары басмасы нигезендә **боерык бирәм:**

1. Юридик затлар исемнәрендә “Татарстан Республикасы”, “Татарстан” атамаларын һәм алар нигезендә ясалган сүзләр һәм сүзтезмәләрне (шул исәптән кыскартылмаларны да) куллануга Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2012 елның 14 июнендәге № 01-02/40 номерлы (2013 елның 22 октябрендәге № 01-02/130 номерлы, 2014 елның 19 августындагы № 01-02/312 номерлы, 2014 елның 21 ноябрендәге № 01-02/495 номерлы, 2015 елның 13 августындагы № 01-02/584 номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) боерыгы белән расланган Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

“2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты” таблицасының 2.14 пунктын түбәндәге редакциядә язарга:

| | | |
|---|---|---|
| “2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналар һәм бүлмәләргә, гариза бирүчеләр көтеп утыра һәм кабул ителә торган урыннарга, шул исәптән әлеге объектларның Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә инвалидлар өчен уңайлы булуын тәэмин итүгә, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртипләре турындагы күрсәтмә, текст рәвешендәге һәм мультимедиа мәгълүматны урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә | Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга киртәләрсез керә алуы (бинага уңайлы керү-чыгу һәм бина чикләрендә уңайлы хәрәкәт).<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы күрсәтмә, | |

| | | |
|---|---|---|
| таләпләр | текст рәвешендәге һәм мультимедия мәгълүмат гариза бирүчегә уңайлы урынга, шул исәптән инвалидларның мөмкинлекләре чикләнгәнлеген исәпкә алып урнаштырыла.” | |

Министр Л.Ю.Глухова